РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

23.10.2015 ел №12

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
территориаль сайлау комиссиясе
составына билгеләү өчен кандидатура
тәкъдим итү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 6 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 15 статьясындагы 6 өлеше нигезендә Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе составына билгеләү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә 1968 елда туган, сайлау комиссиясендә эшләү тәҗрибәсе булган (Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе рәисе булып тора), югары белемле, Контроль-хисап палатасы Рәисе Әхмәдуллин Рамил Исмәгыйль улы кандидатурасын тәкъдим итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрергә.

Муниципаль район
башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин